ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 май, 2021 ел №7/10

Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында» 2009 елның 25 февралендәге ПУ-97 номерлы Указы, шәһәр Уставының 28 статьясының 2 өлеше 36 пунктчасы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/23, 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11, 2013 елның 29 августындагы 26/15, 2015 елның 22 октябрендәге 2/19, 2016 елның 15 декабрендәге 13/11, 2018 елның 10 августындагы 26/14 номерлы Карарлары редакциясендә), түбәндәге эчтәлектәге 12.2 пунктын өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«12.2. Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервы барлыкка килергә мөмкин. Кадрлар резервын формалаштыру тәртибе, кадрлар резервын формалаштыру буенча конкурс комиссиясе турында нигезләмә, кадрлар резервын формалаштыру буенча конкурс комиссиясе составы шәһәр Хакиме карары белән раслана.».

2. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең идарә кадрлары резервын формалаштыру тәртибе турында» 2012 елның 20 апрелендәге 18/14 номерлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2012 ел, 4 маендагы, 34 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2012 ел, 23 маендагы 39 санында басылган;

2) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында 2013 елның 29 августындагы 26/15 номерлы Карарының 5 пунктын.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф. Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев